СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2019 г.Зеленодольск № 267

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу хакындагы Нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инвестицион активлыкны арттыру, шулай ук муниципаль миилекне нәтиҗәлерәк һәм рациональ файдалану максатында, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәте турындагы мәгълүматны ачу хакындагы бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры урынбасары** **К.С. Антипов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

Зеленодольск шәһәре Советы
2019 елның13 ноябрендәге
267 номерлы Карары проектына
карата кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу хакында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу турында нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Дәүләт сере турында» 1993 елның 21 июлендәге 5485-1 номерлы Федераль законнар, «Муниципаль милек реестрын җирле үзидарә органнары тарафыннан алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының боерыгы нигезендә.

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль шулай ук аны ачу ысуллары, тәртибе һәм сроклары, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге (алга таба - Зеленодольск шәһәре) муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәндә барлык кызыксынучы затлар файдалана алуны тәэмин итү күздә тотыла.

1.3. Зеленодольск шәһәренең муниципаль милкен исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты) тарафыннан бирелә. Сорала торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булса, мәгълүмат бирүдән баш тарту очрагы мөмкин.

1.4. Юридик затлар мәнфәгатьләренә зыян китереп, бирелгән мәгълүматны куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Зеленодольск шәһәренең муниципаль милке турындагы мәгълүмат Зеленодольск шәһәре милкендә булган муниципаль милек реестрында (күчемсез милектән тыш) теркәлгән белешмәләр, шулай ук Зеленодольск шәһәре милкендә булган, «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм

җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль учреждениесенең мәгълүмат базасындагы җир кишәрлекләре турында белешмәләр күләмендә бирелә.

1.6. Зеленодольск шәһәренең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм «Интернет» челтәрендә сайтка урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1. «Интернет» челтәрендә Зеленодольск шәһәренең урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милке турындагы мәгълүмат түбәндәге мәгълүмат белешмәләрнең исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматларның законнар белән чикләнгән мәгълүмат булган очраклардан тыш):

Зеленодольск шәһәре муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урыны);

Зеленодольск шәһәре муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урыны);

Зеленодольск шәһәре милкендә булган устав капиталы өлешләре (акция пакетлары) хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урнашу урыны, устав капиталында муниципаль өлеш);

Зеленодольск шәһәре милкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар, бүлмәләр, җир кишәрлекләре) исемлеге (исеме, урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, куллануны чикләү, өченче затларның хокукларын чикләү);

Зеленодольск шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) ;

муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар;

Зеленодольск шәһәренең милек хокукындагы мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәр;

Зеленодольск шәһәре милке хокукындагы мөлкәтне хосусыйлаштыру буенча алыш-биреш нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

Зеленодольск шәһәрен хосусыйлаштыру прогноз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Зеленодольск шәһәренең муниципаль милеге турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылырга мөмкин.

2.2. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар, финанс елы тәмамланганнан соң, дүрт айдан да соңга калмыйча 1 январь торышына ел саен Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә

Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында басылып чыгарга тиеш (http://zelenodolsk.tatarstan.ru).

2.3. Зеленодольск шәһәре муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны ачу, аларны хосусыйлаштыру турындагы законнарда билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Зеленодольск шәһәре муниципаль милке реестрында теркәлгән аерым милек объектлар буенча мәгълүмат кызыксынган затларның мөрәҗәгате буенча хат рәвешендә яки Зеленодольск шәһәре муниципаль милек реестрыннан өземтә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яисә аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) мөрәҗәгать кергән көннән соң 10 көннән дә артык булмаган вакыт эчендә ЗМР Башкарма комитеты тарафыннан бирелә.

3.3. Зеленодольск шәһәре муниципаль милек реестрыннан өземтәләр түбәндәгеләргә бирелә:

исәпкә алу объектлары хокукына ия булучыларга яисә аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объекты хуҗасыннан яки аның законлы вәкиленнән ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы, «Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенә;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына;

дәүләт хакимияте федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга;

салым органнарына;

җитештерүдә исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокуклары белән бәйле эшләре булган судларга, хокук саклау органнарына, суд приставларына-башкаручыларына;

Федераль монополиягә каршы органга һәм Татарстан Республикасында аның территориаль органына.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга, Зеленодольск шәһәре муниципаль милке реестрында исәпкә алу объектлары барлыгы турында гына мәгълүмат бирелә.

3.5. Соратыла торган мәгълүматны бирүдән баш тарту нигезле булырга тиеш, һәм ул язма рәвештә бирелә.

Соратыла торган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен түбәндәге сәбәпләр нигез булып тора:

мөрәҗәгатьтә закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган белешмәләр соратып алына;

мөрәҗәгатьнең эчтәлеге әлеге затны кызыксындыра торган объектны ачыкларга мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Зеленодольск шәһәренең муниципаль милек реестрында мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән.